# КАРАР

17 ноябрь 2021 ел №1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Красная Гора авылы җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 17 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районының Красная Гора авылы, Түбән Өскебаш авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә хәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 85 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә риза булырсызмы?

- Красная Гора авылында юлларны кыш көне карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- видеокамералар алу (сатып алу) һәм урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- Красная Гора авылында урнашкан артезиан скважиналарына насослар сатып алу;
- Су башняларына койма тоту( материал сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- Красная Гора авылындагы чишмәне ремонтлау; материал сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- янгын сүндерү машинасына запчастләр сатып алу; кую; янгын сүндерү машинасына ремонт ясау; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган ,җыенда катнашучылар исемлегенә, 75 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 40.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 40 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Красная Гора авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.
2. Сорау буенча карарны танырга: «2022 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Красная Гора авылы, Түбән Өскебаш авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 85 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешеп торасызмы:

- Красная Гора авылында юлларны кыш көне карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- видеокамералар алу (сатып алу) һәм урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Красная Гора авылында урнашкан артезиан скважиналарына насослар сатып алу;

-Су башняларына койма тоту( материал сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

-Красная Гора авылындагы чишмәне ремонтлау; материал сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

-янгын сүндерү машинасына запчастләр сатып алу; кую; янгын сүндерү машинасына ремонт ясау; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән гражданнар җыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Авыл җирлеге башлыгы Н.М.Мөхәмммәтҗанов